# ОЧЫП КАЙТАМ

*И.МӘҖИТОВ көе*
*Д.ГЫЙСМЕТДИНОВ шигыре*

Өянкеләр саный чакрымнарны,
Колач җәя миңа каеннар.
Әй, авылым, очып кайтам сиңа,
Бәхет хисләрендә коенам.

*КУШЫМТА:*
Йөгерә — йөгерә тау астына төшәм,
Чишмәләрдә иренем чылатам.
Ә кичләрен тальян гармун тартып,
Әнкәй, сине тагын елатам.

Искә төшер узган яшьлегеңне,
Оныт, әнкәй, оныт картлыкны.
Син бу җирдә хәсрәтне күп күрдең,
Татып калчы бераз шатлыкны.

*КУШЫМТА*

Өянкеләр саный чакрымнарны,
Боегып кала таныш каеннар.
Авылыма очып кайтсам да мин,
Китүләре бигрәк кыен ла.

*КУШЫМТА*